**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Тауасты Байлар торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**12.11.2025 ел** **№6**

Россия Федерациясенең 2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 45, 69 маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының "Тауасты Байлар авыл җирлеге" Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге Тауасты Байлар торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге Тауасты Байлар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Тауасты Байлар торак пункты һәм якын-тирә территорияләрнең юл кырыйларын чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тауасты Байлар торак пунктындагы Мирная урамы буенча юлга вак таш сатып алу һәм салу, кышкы чорда юлларны грейдерлау (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү)).

3. Әлеге карарны Тауасты Байлар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы,
Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгы З.С.Гәрәева